**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлегенең Тутай авылында гражданнар җыены карары**

13 октябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлегенең Тутай авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Югары Лашчы авыл җирлегенең Тутай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерүгә (каты коммуналь калдыкларны җыю мәйданчыгын урнаштыру, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу); - Тутай авылындагы торак пункт территориясен төзекләндерүгә (балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, җәйге вакытта территорияне чабу). юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Югары Лашчы авыл җирлегенең Тутай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,

Югары Лашчы авыл җирлегенең Яшевка

авыл җирлеге башлыгы _________ Г.Х.Усманова

Халык җыены секретаре _________ Г.Р.Галеевао